СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ- СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО - ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | №148 (7321) | 10 декабрь, 1991 ел. СИШӘМБЕ | Бәясе 4 тиен.

## Яңа оешма төзелде

6 нчы декабрь көнне яшьләр оешмалары район Советының оештыру конференциясе үтте. Анда конференция делегатларыннан тыш ВЛКСМның республика комитеты хезмәткәре А. И. Пирожков, халык депутатлары район Советының яшьләр белән эшләү, физкультура һәм спорт бүлеге мөдире Ф.Р. Ногманова катнашты.

Конференциянең беренче көн тәртибендә ВЛКСМның район комитеты беренче секретаре Н . М. Мөхәммәтҗанов яңа оешма — яшьләр оешмалары район Советының Уставы, программасы, бурычлары һәм максатлары белән таныштырды. Конференциядә катнашучылар әлеге Уставны кабул итеп, халык депутатларының район Советы каршында яңа оешманы теркәүне сорап мөрәҗәгать итәргә карар кылдылар. ВЛКСМ республика комитеты вәкиле А. И. Пирожков республикада яшьләр хәрәкәтенең бүгенге торышын, ВЛКСМ рескомының финанс хәлен анализлады, яңа алмашка килүче оешмалар турында сөйләде.

Конференциядә яшьләр оешмалары район Советының рәисе итеп Н. М. Мөхәммәтҗанов, аның урынбасары итеп Ә. Х. Шәяхмәтов сайланды. Шунда ук 4 кешедән торган яшьләр оешмалары район Советы идарәсе сайланды.

**Аннан яшьләр оешмаларының республика учредительный конференциясенә делегатлар күрсәтү башланды. Делегатлар итеп яшьләр оешмаларының район Советы рәисе урынбасары Әнвәр Хәйдәрович Шәяхмәтов һәм әлеге идарә члены, район пионерлар йорты директоры Гүзәл Дамировна Әһлиуллина сайланды.**



Шәяхмәт Галиевич Хәсәншин байтак еллар механизатор булып эшләде. Хезмәтен җиренә җиткереп, карусыз башкаруы белән хуҗалыкта хөрмәт казанды. Инде 2 ел элек, аның хисап эшенә сәләтен, төгәллеген, гаделлеген исәпкә алып, Шәяхмәт Галиевичны учетчы итеп күчерделәр. Хәзер ул бу хезмәтне дә тулысынча үзләштерде, аның эшенә карата колхоз идарәсенең дә, механизаторларның да сүз тидергәне юк.

Рәсемдә: Ульянов исемендәге колхоз учетчысы **Ш. Г. Хәсәншин.**

## УКУЛАР БАШЛАНДЫ

9 декабрьдән районда ферма мөдирләре һәм баш зоотехниклар өчен бер атналык зооветукулар башланды. Район ветеринария станциясендә үткәрелә торган бу укуда ел үзенчәлекләреннән чыгып терлекчелектәге бурычлар, товарлыклы-сөтчелек, товарлыклы- дуңгызчылык һәм сарыкчылык фермаларында малларны карау, хезмәтне оештыру һәм аңа түләү, үрчем алу һәм аны саклау буенча район авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе һәм ветеринария станциясе белгечләре чыгышы планлаштырыла. Аны беренче көнне район авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе начальнигы Ә. Н. Рәхмәтуллин районда терлекчелекнең бүгенге торышына гомуми анализ ясау белән ачып җибәрде.

## Ишеттегезме әле...

*Тольятти машина төзүчеләре өчен алар эшләп чыгара торган «Лада» һәм «Нива» машиналары үзенчәлекле валюта ролен үти. Өлкәгә кирәкле җиһазлар һәм материаллар сатып алу өчен «Волга» автозаводы 310 машина бүлеп бирде. Машиналар тракторлар һәм комбайннар өчен запас частьларга, агачка, хәтта конфет кәгазенә алыштырыла.

*Армавирда яшәүче өч сөрхәнтәйнең кеше башыннан бүрек аулап йөрүе бик күңелсез тәгәлләнде. Алар берәү башыннан бүрек эләктереп чабып китүгә, якындагы ир-атлар югалып калмый. Теләләрне бик тиз тотып алалар. Тавышны казакларның шәһәр митингысына җыелган кешеләр ишетеп ала. Казакларның хөкем карары катгый — теге юньсезләрне бөтен халык алдында мәйданда суктырырга.

*Ел ахырына Кытайда халык саны 1 миллиард 116 миллион кешегә җитте.

*Җир тетрәү нәтиҗәсендә Румыниядә 2500 йорт ишелеп төште һәм 2 меңгә якын кеше тән ярасы алды. Корбаннар юк.

x x x

Күптән түгел генә Ватаныбыз башкаласында килограммы 162 сумнан сатылган атаклы «Советская» колбасасын Ярославль шәһәрендә 229 сум 50 тиенгә саталар икән.

Хак сүзле «Золотое кольцо» өлкә газетасы бу аяктан егарлык яңалыкны «Ярославль төкерде Мәскәүгә» дигән баш астында биреп, әлеге патша колбасасын зур сурәте белән бастырган. Өч көннән соң Ленинград проспектындагы универсам директоры Ирина Степанова газета чыгышы бик яхшы реклама булды, дип белдерә. Кибет Ярославль читендәге микрорайонга урнашкан булуга карамастан, сатып алучылар бирегә ябырылган. Бер хатын озакламый туй буласына сылтап, мең сумлык колбаса алган.

Моңа гаҗәпләнергә дә урын юк. Якын көннәрдә генә килограммы 130 сумлык атланмайны да чират торып алып бетергәннәр. Бу аңлашыла да, чөнки ярославльлеләр аның тәмен дә онытып баралар икән инде.

x x x

Француз шәһәре Перигадагы почта маркалары басу типографиясе СССРдан азык-төлек талоннары басарга заказ кабул итте.

*Хәзер бу бик көлке тоелыр, әмма әлеге факт күптән түгел генә беленде. 1946 елда Бөекбританиянең тышкы эшләр министрлыгы СССР дөньяда иң куәтле экономик дәүләткә әвереләчәк дип чын күңелдән ышанган икән.

Ачыкланганча, Британия тышкы эшләр министрлыгы хезмәткәрләре СССРда промышленность җитештерүе күләме 1975 елда Америка күрсәткечләренә тигезләнәчәк дип ышанганнар.

# Тимер чыңы тынмый

Күптән түгел генә дәртле хезмәт белән гөрләп торган басулар серле тынлыкка чумган. Әнә шул иртәнге серле тынлыкны бозып, авыл башында трактор күренде. Салам кибәннәре өстендә шул тынлыкта оеп утыручы көртлекләр, басуга җим эзләп килүче чыпчыклар өере пырхылдап һавага күтәрелде. Тракторчы исә туп-туры басуга үтте, арбадан тиресен бушатты да янә килгән юлына чыкты. Ул Евгений Сухов иде. Әле күптән түгел генә изү чишеп, кыр шаулатып эшләп йөргән механизатор бүген кышкы сезонга фермага эшкә килгән. Нинди генә хезмәткә алынса да намус белән эшләүче Евгений Александрович бирелә тирес чыгаруда да сынатмый.

**Әнә шундый игенче хезмәтенә үзен тулысынча багышлаган, җирне бөтен йөрәге белән яраткан, техникага гашыйк, сайлаган һөнәренә күңеле белән турылыклы булган авылдашларым турында уйлыйм. Хәбир Вәлиев, Хәким Нуруллин, Гариф** Хәлимов, Гаяз Хәсәнов, Гата Гыйбадуллин 30 елга якын туган басуларында җир сөрәләр, иген үстерәләр. Елның-елында алар сафына яшьләр кушыла. 3 ел инде механизаторлар аренда звеносына берләшеп, тотрыклы уңыш яулыйлар.

Мәсәлән, Илһам Хафизов җитәкчелегендәге 11 кешелек звеноның күркәм эшләре турында искә алмый мөмкин түгел. Алар бөртекле-кузаклы культураларның һәр гектарыннан 21,3 центнер, шикәр чөгендереннән 220 центнер уңыш җыеп алдылар. **Быелгыдай корылыклы елны шушындый уңыш җыеп алу зур куаныч. Звено членнары Хәбир Вәлиев, Таһир Хәлимов, Хәкимулла Нуретдинов, Хәниф Хафизов, Сәлим Хәниев, Юныс Мортазин һәм башка тырыш механизаторларның җирләрне** агротехника кушканча эшкәртү, ашламаларны вакытында тигезләп сиптерү, чәчүлекләрне яхшы караву нәтиҗәсендә ирешелде бу уңышка.

Шакирҗан Әндәрҗанов җитәкчелегендәге звено егетләренең дә хезмәте мактаулы.

Уйларымны мастерской ягыннан ишетелгән тимер чыңы бүлде. Игенче авылдашларымның бүгенге шөгыле, язгы чәчү хәстәрлекләре белән кызыксынып мастерскойга юнәлдем. Биредә киеренке эш кайный. Әле тегендә, әле монда механизаторларның һәм мастерской белгечләренең җитди, кайгыртучан йөзләре күзгә чалына.

**Хәким Нуруллин, Ислам Хәлимов, Сәгыйть Нәбиуллин, мастерской белгечләре ярдәмендә үзләре идарә иткән тракторларга ремонт ясыйлар, Тагылма инвентарьны ремонтлау өчен махсус җылытылган, якты утлар куелган цех булдырганнар.** Иң тырыш механизаторлар — Хәниф Хафизов, Рәшит Фәйзуллин, Әхәт Әхмәтов, Илһам Галимҗанов 15 чәчкечне, 12 культиваторны ремонтларга керешкәннәр. Чәчкечләрнең яртысы ремонтланган инде. Январь ахырына ремонтны тулысынча төгәлләү өчен тырышып эшлиләр.

Тормышыбызның ярлылыгы, җитешсезлеге механизаторларның эшен нык тоткарлый. Запас частьләрнең булмавыннан зарланалар.Электрик Наил Миннеханов, токарь Виктор Малыгин, Галимҗан Галимовларның эше бик киеренке. Механизаторларның әле берсенең, әле икенчесенең гозере төшеп тора.

**— Хезмәтеңә чын мәхәббәт булмаганда, эшеңне ләззәт, шатлык тоеп башкармаганда, бик кыендыр ул, — диләр тимерчеләр Минталип Мөхәммәтвәлиев һәм Мөкатдәс Мөхәммәтшин. Алар икесе дә армия хезмәтеннән соң ашкынып туган авылларына кайтып эшкә керештеләр.** Минталипның тимерчелектә эшли башлавына 6 ел вакыт үтеп тә киткән. Мөкатдәс эретеп ябыштыручы һөнәре алып, шунда эшләде, аннан тимерчелеккә алынды. Егетләрнең бүгенге көндә, кем әйтмешли, «эшләре муеннан». Үзләренең төп вазифаларыннан тыш, җиңел һәм авыр тырмаларны ремонтлыйлар, сафтан чыккан тешләрен алыштыралар. Шөрепләрне, болтларны, ышанычсыз сыныкларын алыштыралар. Аларның кулларына күз иярми. Механизаторларның заказлары беткән арада тизрәк эшләп калырга ашыгалар, 400 дән артык тырманы яхшы сыйфатлы итеп әзерлек сызыгына куярга тырышалар.

Әйе, игенченең эше шундый, ел әйләнәсе бетми, **икмәк табынга бик күп мәшәкатьләр, тынгысыз, йокысыз төннәр, аяусыз хезмәт аша гына килә.**

**Үз хезмәтләренә чын күңелдән бирелгән җитди йөзле, уңган механизаторларга карыйм да, киләсе елларда да мул уңышлар алуга өмет, ышаныч арта.**

**М. УСМАНОВА.**
«40 лет Победы» колхозы.

